Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты

Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

31 октябрь, 2023 ел № 27

«Кибәч авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 2022 елның 16 сентябрендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 20 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Кибәч авыл җирлегендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 2022 елның 16 сентябрендәге 16 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов